Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!

ISSN 0136-7110


Чаян



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ НОЯБРЬ * 2022 * КАЗАН

11

Александр АЛЁШИН





Рөстәм ЗАРИПОВ

ЖЫЕН

Кайнар нотыклар ясала
Язучылар жыенында,
Иснәнеп кабул итәсең
Куесын да, сыегын да...

Мәмрәп тә кителә кайчак,
Кемдер бушатканда эчен,
Менә тагын берәү сөйли:
"Мин яшәдем милләт өчен!

Мәйданда азатлык даулап,
Селтәп мунчала кылычны,
Аңлапмы, аңламыйчамы
Дәү абзыйга нык булыштым...

Яудырган гаепләүләрем
Шуның файдасына чыкты, –
Үзәк алдында идеаль
Толерант образ калыкты...

...Спарринг партнер сыйфатында
Йөргән чорым калды ерак,
Инде Гүзәл Яхинаны
Талку өчен житте чират...

Ник бар да укый Гүзәлне,
Һәм мактыйлар күккә чөеп?!
Әллә ничә премияләр
Тапшыралар аңа өеп...

Мин дә иҗат итәм ләса,
Татарым, дип, ярсып-дулап.
Тукайдан бүләк килмәде
Житмешемә дә турылап...

Социаль челтәрне ярып,
Ишетәсездер үкерү:
"Миңа премия бирмәү –
Милләт битенә төкерү!.."

...Кемнеңдер төрткәләвеннән
Шул мәлдә уянып китәм,
Бар да кайтырга кузгалган, –
Жыенныбыз тәмам икән...

Алмаз ХӘМЗИН

Сиңа – житмеш, миңа – куш биш.
Ә төшебез – бертөсле.
Син "чакканга" мин кул чабам,
VIP катлам – чапмый берсе.

Илдар НӘФИЕВ





ШОМБАЙ болай диде...

Хөрмәтле Чаян! Заманында бездә Советлар иле иде, ә хәзер, гафу итегез, лайфхаклар, ягъни киңәшләр иле. Интернет төрле файдалы киңәшләр белән тулган. Сәламәтлек, йорт хуҗалыгы, автомобиль, бала тәрбияләү, финанслар, женесләр мөнәсәбәте – барысына да киңәш-лайфхак табыла. Ә аларның бер-берсенә каршы килүе беркемне дә борчымый, ахрысы...

Р. ДӘМИНОВА

әлмәт

– **Шуны әйтергә телим, –** диде Шомбай агабыз хатны укып чыккач, **– галимнәр күптән инде файдалы киңәшләрнең зыяны турында кисәткәннәр иде.**

Ринат АБЗАЛОВ

КӨЗГЕ ЯФРАК

Ярсу җилләр йолкый аккаенны,
Соңгы яфракларын коялар.
Елый каен – алтын таңкаләрен
Төпләренә җыеп өяләр.
Аккаенның кипкән яфраклары
Кара җирдә, череп, үләрләр.
Ә аларны кырыс көзге җилләр
Тузан-туфрак белән күмәрләр...

...Язлар килер.
Яшь бөреләр белән
Ямьләнерләр шәрә ботаклар.
Ә аларга яшәү көче биргән –
Череп үлгән көзге яфраклар.

ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР...

Әгәр кешенең күңелен яуларга телисез икән, аңа бәхәстә җиңәргә бирегез.

Кешегә аның үзе турында сөйлә, һәм ул сине сәгатьләр буе тыңлап утырачак.


Чын ялгызлыкны зур шәһәрдә эзләргә кирәк.

Әгәр мин яхшы шигырь укырга телим икән, мин аны язам.

Гомер – ул җыр, ә аның кушымтасы – үлем.

(Тормыш белгечләре мәҗлесендә язып алынды)

Михаил ЛАРИЧЕВ





Валентин ДРУЖИНИН

Операциягә бирегез...

Тарихның төрле вакытларында җәмгыятьнең иң үткен һәм югалып калмас катлавы, мөгаен, мошенникләрдыр. Тормыштагы теләсә нинди үзгәреш, яхшы яккамы ул, начаргамы – кулга чиста булмаган бәндәләргә яңа мөмкинлекләр ача. Каушап калган гади кеше язмышның яңа борылышы аңа нәрсә әзерләгәнен аңларга тырышып, башын кашып торганда, аферист һич тә шикләнми – ул, һичшиксез, табыш.

Каракларның эресе дә, вагы да соңгы вакыйгаларны – махсус хәрби операцияне, өлешчә мобилизацияне һәм аларга бәйле башка әйберләрне – игътибарсыз калдыра алмады. Күптән түгел Казанда, бу хәлдән файдаланып, баерга теләгән берәүне тотканнар. Дагстанда туып-үскән Гермет Нәҗметдинов классика персонажы – лейтенант Шмидтның улы булып карарга карар кылган. Тыйнаклык турында онытып, ул үзен Дәүләт Думасының иминлек һәм коррупциягә каршы тору буенча рәисе урынбасары итеп билгеләгән. Мордовия һәм Татарстанда хакимиятләргә шалтыратып, ул "коллега"ларын патриот булганнарын онытмаска һәм Ватанга матди ярдәм күрсәтүләрен үтенгән. Төгәлрәк әйтсәк, махсус операция өчен акча бирергә һәм качкыннарга матди ярдәм күрсәтергә. Әгәр Мордовиядә аферист шулай итеп 234 мең сум суырып алган булса, Татарстанда Лениногорск районы башлыгы аны кулыннан тоткан. Нәтиҗәдә, "коррупциягә каршы көрәшче"не тотканнар, кулга алганнар һәм судка биргәннәр.

Ә Чаллыда "гуманитар ярдәм җыю" белән шөгыльләнүче мошенниклар эшмәкәрләргә чын мәгънәсендә һөҗүм оештырганнар. Ялган санитария табиблары, Роспотребнадзор хезмәткәрләре исеменнән, махсус хәрби операциядәге хәрбиләргә матди ядәм күрсәтүне сорап теңкәләренә тигәннәр. Кыскасы, "операциягә акча бирегез"!

Севастопольдә бер диңгез офицеры, повестка да алмаган килеш, вакыйгаларның көтелмәгән борылышларына әзерләнеп торырга булган. Иҗтимагый челтәрдә "Стрелок" дип аталган махсус экипировка интернет кибете табып, ул 50 мең сумлык хәрби кирәк-яракларга заказ ясаган. Ләкин офицер товарны ала алмаган: "Стрелок" та, акча да юкка чыккан. Мондый мәкерлелек көтмәгән ир кеше, Интернетта берни дә эзсез югалмый дигән гыйбарәне исенә төшереп, полициягә мөрәҗәгать иткән...

Ә менә Чаллыда мәктәп җыештыручысы белән ике "мобилизацияләнгән" ирнең танышуы полициядә тәмамланган. Беркөн алар урамда бер хатын янына килеп, аңа үзләренең сугышка китәчәкләре, ә тамаклары ач булуга зарланганнар. Олы җанлы хатын аларың тамакларын туйдырырга булган, ләкин телефоныннан кибеткә түләү ясау мөмкинлеге булмаганы ачыкланган. Ачык күңелле, беркатлы хуҗабикә үзенең телефонына банк кушымтасы урнаштырырга, ә түләгәннән соң аны юкка чыгарырга тәкъдим иткән. Ир-егетләр бер буханка ипи, бер пакет көнбагыш, ике шешә сыра сатып алганнар, ә аннан соң аларны "военкоматка чакыртып алганнар". "Хәрбиләр" белән бергә хатынның счётыннан өч мең ярым сум акча да юкка чыккан.

Гомумән алганда, көтмәгәндә башланып киткән мобилизация кулга чиста булмаган бәндәләр өчен төпсез алтын сандыкка әйләнде. Тиз генә оешып, алар яхшы түләү өчен өеннән аерылырга теләмәүчеләрне броньлы компьютер әһеленә, хәрәкәтсез ятучы инвалид йә СПИД йоктырган мокытка әверелдерүче күпсанлы сайтлар ачып җибәрделәр. Акча өчен үзләрен хәләл җефет, ә балаларын кыз-ул сыйфатында тәкъдим итүче күп балалы хатыннар активлашты. "Балалы хатын" төшенчәсе көтмәгәндә мәгънәсен уңай якка үзгәртеп куйды...

Мошенникларның яңа ысуллары турында безне даими рәвештә кисәтеп торалар, ләкин мондый мәгълүматлар сөтнең каймагы алынып, ә гражданнар төп башына утыртылгач кына билгеле була. Нишлисең бит, бер үк тырмага кат-кат басу – безнең милли традиция шул. Тагын бер тапкыр кисәтәсе генә кала: уяу булыгыз, аферистларның хәйләләренә бирелмәгез, аларның кыланышлары турында тиешле урынга хәбәр итәргә онытмагыз.

Людмила САФИУЛЛИНА





Михаил ЛАРИЧЕВ



Валерий ТАРАСЕНКО



Игорь КИЙКО





• • •

Карт режиссерларга, композиторларга, артистларга, бизнесменнарга кияүгә чыгалар да, янәсе, яратып чыктым, диләр. Карт слесарьларга чыгучыларны бер дә ишеткәнем юк.

• • •

Компьютерлар һәм шуларга кирәк-яраклар сату фирмасына шалтыраталар:

– Исәнмесез, сездә сыек мониторлар бармы?

Сатучы:

– Сезгә ничә литр: 15, 17, 19?..

• • •

Мәчеләргә бирә торган ашамлыкны башкача тыйнаграк атап булмыймы? Нишләп минем мәчем "атланмайлы соус болгатылган кролик рагуы" ашый, ә мин – сосиска белән макарон?

• • •

Ике сыер сөйләшә.

– Беләсеңме, безне башта сөтебезне эчәргә, соңыннан суеп, итебезне ашар өчен генә тоталар, ахрысы.

– Син һаман шул фетнә теориясен кузгатасың...

• • •

– Мин бер кызга гашыйк булдым, ул татар. Нәрсә эшләргә микән?

– Өчпочмак.

• • •

Иң озын йокының тарих дәресендә булуы теркәлгән – бер укучы XV гасырда йокыга талган һәм XVIII гасырда гына уянган.

• • •

– Интернет чын тормышка бик тартым.

– Нишләп?

– Менә кызлар янына барып кайттым – ике вирус эләктердем.

• • •

Тамада:

– Кадерле дуслар! Бүгенге туйда иң якын кешеләр һәм туганнар җыелган. Гаугага чыгарырга бик кыен булачак, ләкин мин профессионал!

• • •

Минем яшьтә инде ниндидер булмаган якты киләчәкне күтәргә кирәк түгелдлер. Никадәр яшәргә язса, шунысы якты.

Абау!

РИШВӘТЧЕЛЕ БӘЙГЕСЕ

Татарстан ришвәтчелек буенча беренчелекне ычкындырмый. Соңгы ярты ел эчендә 261 очрак теркәлгән. Әмма бу саннар республика рәхәткә чыккан коррупционерлар өлкәсе дигәнне аңлатмый, әлбәттә. Моны хокук саклау органнары эшенең тискәре түгел, ә уңай күрсәткече итеп кабул итәргә кирәк. Икенче урында Мәскәү (225), аннан соң Мәскәү өлкәсе (171) бара. Ә менә Карачай-Чиркәс өлкәсе, Хакасия һәм Адыгейда бер генә ришвәт алу очрагы да теркәлмәгән. Сез моңа ышанасызмы?

ПИРАМИДА ТӨЗҮЧЕЛӘР

Республикада яшәүчеләр пирамида төзүчеләргә актив рәвештә булышлык күрсәтәләр. Хәзерге вакытта хокук сакчыларның күзәтүе астында ике дистә чамасы финанс махинацияләре белән шөгыльләнүче компания тора. Аларның уналтысына карата җинаять эше кузгатылган инде. Ел эчендә андый фондлар оештыручы 22 кеше тоткарланган. Ләкин мошенниклар белән кискен көрәш алып барылуга карамастан, пирамида төзүчеләр тарафыннан 13 мең татарстанлы зыян күргән, ә акчалата югалтулар 3 миллиард сум тәшкил иткән.

ЯҢА КРӘСТИЯННӘР

Татарстанда җиде фермер грантлар белән "шаярткан" өчен суд каршында җавап тотачак. Компания крәстиян-фермер хуҗалыкларын үстерү максатына дәүләт ярдәме алган. Ләкин алынган акчалар изге максатлар өчен файдаланылмаган. Авыл хуҗалыгы министрлыгы өчен яңа "крәстияннәр" ялган документлар әзерләгәннәр. Фермерлар республика бюджетын барлыгы 32 миллион сумга җиңеләйткәннәр.

ТҮЛӘҮЛЕ ФӘН ӘҺЕЛЕ

КФУның Алабуга филиалында студентлар биология һәм химия кафедрасы мөдиренә зачётларын билгеләр өчен акча бирмәгәннәр. Студентларның белеменә караганда, мөгаллимне күбрәк аларның акчалары кызыксындырган. Прогулчылар өчен зачёт бәясе 3 мең сум булса, калганнар өчен 2 мең сум торган. Ә чын белемен күрсәтергә теләүчеләрне доцент "батырган" һәм зачётны икеләтә суммага тапшырырга мәҗбүр иткән. Ришвәт алуын ул фәнни журналда мәкаләләр бастыру өчен акча кирәк булуы белән аңлаткан.

Вячеслав ШИЛОВ



Александр АЛЁШИН



Рашат НИЗАМИ

БАШ ХӘРЕФ

Баш хәрефтән фәкать языла торган
Ике сүз бар – туган телемдә:
ӘНИ дигән, ВАТАН дигән сүзләр
Мәңге китмәс безнең күңелдән!

КАЙЧАКЛАРНЫ...

Кайчакларны исем китеп карыйм
Меңәр каптырмалы дөньяга:
Бер уйласаң, тәмам картайган ул,
Курпылары гына өр-яңа!

ТӨНГЕ МӘЧЕ

Йокламыйча, җитез чабып кына,
Төнге мәче, кая барасың?
Синең белән Ай да узып бара
Тәүлек белән гасыр арасын...

ЧИНОВНИК


Бармакка бармак сукмыйча
Яши кәнәфи корты.
Майтарган эшенә хәтле
Үзе күк ярты-йорты...

КИСЛОРОД


Бер тамчы кислород җитми кала
Ярга ыргытылган балыкка.
...Кислород мендәре җитми кала –
туган телгә,
Хезмәт хакы җитми халыкка.

Мин Ходайдан сорыйм: туган телгә
Бирче, зинһар, кислород мендәре...
Ләкин "мендәр" безнең кулда түгел,
Аңа рөхсәт кирәк элгәре!

Николай ВОРОНЦОВ



Валерий ТАРАСЕНКО



Александр БРЮХАНОВ

БАРЫСЫ ДА О'КЕЙ

Ялгызы стена янына басып, Түшкин кунакларны күзәтеп тора иде. Ниндидер таныш булмаган бер бәндә аның янына кара тәнле ханымны алып килде...

– Бу Лиз була, – диде ир кеше. – Ул үзе америкалы, ләкин безнеңчә сөйләшә белә, күңел ачыгыз, – һәм шунда ук кулларына шампанский салынган бокаллар тоткан кешеләр арасына кереп югалды.

«Кемнеңдер хатыныннан качасы килгән, ә минем ни эшем бар монда» – дип уйлап куйды Түшкин, күзләрен мөлдерәтеп.

Чибәр күренә үзе, тик менә нәрсә турында сөйләшергә икән...

«Кайда, кем булып эшли икән. һәм күпме ала икән...» – дип сораргамы, әллә кызыклырак темалар табаргамы?

Юк! Эш урыны һәм хезмәт хакы турында сорашу аларда әдәпсезлек булып санала бугай... Шулай дөрестер дә, чөнки андый сораудан соң кешеләр бер-берсенә битараф булып калалар...

Бәлки футбол турында сөйләшеп караргадыр? Юк, кирәкми. Беренчедән, ул хатын-кыз, икенчедән, аларда футболга мөнәсәбәт бөтенләй башка... Ә политика турында? Ә бу провокация булса?

Нәрсә сорарга соң инде? Тумышы белән каян ул? Кайда яши? Монысы да акчага барып бәйләнә...

Гаиләсе бармы? Мондый сорау тагын да әдәпсезрәк була бугай...

Балалары бармы? Бәлки ул бала табуның дошманыдыр? Хәтере калуы бар...

«Ә минем анда нинди эшем бар соң?» – диде эченнән генә Түшкин һәм турыдан-туры ярып салды:

– Хау ар ю? Эшләр ничек?

– О'кей, – диде американка, уйлап та тормыйча...

– Минеке дә шулай ук, – дип җавап бирде ул, сорауга әзерләнеп, һәм шампанский йотып куйды.

Әңгәмәдәше дә шуны ук кабатлады һәм безнеңчә сорап куйды:

– Ә сез кайда эшлисез?



Виктор БОГОРАД



Виктор ФЁДОРОВ



Вячеслав ШИЛОВ



Дамир МОРТАЗИН

НӘРСӘ ӨЧЕН БУЛСА ДА БУЛА...

Шикләевнең полиция бүлеге яныннан үтеп барышы иде. Ирексездән күзе "Игътибар, розыск!" дигән стендка төште. Кемнәр генә юк монда, Ходаем! Нинди йөзләр! Нинди статьялар! Менә бер сакаллы, зыялы затның фотосурәте – а-ля доктор Айболит. Аның турындагы аңлатмаларны укысаң – зур аферист. "Күрәсең, байтак беркатлы кешеләрнең миллионлаган акчаларын алып, яхшы гына бизнеска тыгам дип, чит илгә тайган..." – дип, ачулы фикер йөгереп узды Шикләевнең башында. Ә менә кабартылган иренле, караңгы чырайлы ханым статьясы – кеше үтергәнлеккә. "Мөгаен, үзе иренең башына җиткәндер йә пластика ясатырга акча бирмәгәндер тегесе..." – дип фикер кылды Шикләев, белдеклелегенә сокланып. Чираттагы җинаятьче чыраена карап, ул шуны ачыклады: "Монысы инде зур бандит – олы юлдан! Мордасы бигрәк хәтәр..." Юк икән, никахлашып йөрүче аферист. "Нигә шундыйларга кызыга бу хатын кызлар?" – дип, күңелсез уйларга батты Шикләев, стендта ялтыраган үзенең шәүләсенә карап.

Соңгы фотосурәткә җиткәч, ул катып калды. Аңа аларның фирма директоры Ихтыярсызов карап тора иде! Фото астындагы мәгълүмат мондый аңлатма биргән: "Эзләнүдә сексуаль маньяк... Төрле фамилия астында яшеренеп йөри... Күзгә чалынган очракта тиз ара хәбәр бирергә", диелгән.

"Менә сиңа мә! – дип шаклар катып карап торды ул аңа. – Абруйлы директор дәрәҗәсендә качып ята икән бит маньяк. Әле сексуаль дә икән..."

Ул игътибар белән кабат-кабат фотога карап алгалады. Төгәл ул – директор Ихтыярсызов, бары күзлексез һәм галстуксыз. "Кара син аны – ничек кыяфәтен, килешкилбәтен үзгәрткән, кабахәт! – дип куйды ул үзалдына. – Хәбәр бирим әле кирәкле җиргә..."

Полициядә Ихтыярсызовны яхшылап тыңладылар, сөйләгәнен язып бардылар һәм чара күреләчәген әйттеләр. Икенче көнне фирмада бу хәбәрне ишетеп, шау-шу килделәр. Шул чактук шефларын кулга алдылар, бөтен кәгазьләрен, ноутбугын да калдырмадылар. Тиздән берәмберәм хезмәткәрләрне полициягә чакырта башладылар. Шикләевкә дә чират җитте.

– Нәрсә? – дип сорады ул тикшерүчедән. – Гаебен таныдымы?

– Таныды, – дигән җавап ишетелде.

– Чынлап маньякмы? – дип, төгәл беләсе килде Шикләевнең.

– Юк, ике тамчы су кебек бер-берсенә тартым...

– Нәрсәгә таныды соң ул гаебен? – дигән сүзен әйтергә мәҗбүр булды Шикләев гаҗәпләнеп.

– Салымнар түләмәгәнлеген, зур суммаларын сул фирмалар аша үзләштергәнен һәм күп санда ришвәт белән шөгыльләнгәнен әйтеп салды, – диде тикшерүче. "Без шундук сиздек аның бик нык борчылганын... һәм мәҗбүр иттек... Хәзер СИЗОда ялганламыйча хаклыкта ничек булганын яза... Ә сезгә уяу булганыгыз өчен рәхмәт!

"Менә бит ә! – дип уйлады Шикләев полициядән чыкканда. – Теләсә нинди җитәкчене судсыз-нисез, тикшерүсез дә утыртырга була, дип юкка әйтмиләр икән шул һәм, гомумән, нәрсә өчен булса да була..."

Николай ВОРОНЦОВ





Ринат АБЗАЛОВ

Виктор ВЕСЕЛОВ

Диспут

– Кадерлем! Син бит сүз бирдең! Әйткән сүзеңне тота бел.

– Чибәрем! Кайсыдыр борынгы философ, беләсеңме, нәрсә дигән: «Мөмкин булмаган нәрсәне үтәргә генә вәгъдә ит! Шул чакта үзең алдында оят булмас». Менә мин вәгъдә иттем дә. Мөмкин булмаганны...

– Сүз тота белү – ир кешенең төп сыйфаты!

– Син, ичмасам, сыйфатның нәрсә икәнен беләсеңме? Гегель сүзләрен исеңә төшер! Ул болай язган: «Сыйфат ул үзе булган нәрсә белән нәрсәдер ясаучы».

– Син үзеңнең нәрсә әйткәнеңне аңладыңмы соң?

– Әлбәттә. Әгәр дә бу постулатның эчке мәгънәсен онытып, ул Нәрсәдерне мин дип фаразласак...

– Хыялга баттың, ахрысы! Син «Нәрсәдер» түгел, ә бушлык! Минем арттан йөргәндә, исеңдәме бар нәрсәдә ярдәм итәргә сүз биргән идең...

– Ә бу турыда Сократ менә нәрсә дигән: «Кеше! Ярдәмне үзеңнән генә көт!» Нәрсә, ул синең өчен авторитет түгелмени?

– Бөтен ирләр – бәдбәхетләр!.. Хәтта Сократ та...

– Гүзәлем, син хаклы түгел. Бу – ялгышу, аның асылында өлгереп җитмәгән эмпиризм ята. Ә аннан котылырга кирәк... Ничекме? Бик гади генә! Үз-үзеңне эзистенция итеп кабул итәргә өйрән.

– Нәрсә, нәрсә?

– Экзистенция буларак. Үз өстеңдә эшләргә кирәк. Әйт әле, син кайчан соңгы тапкыр Сартрны укып чыктың? Катлаулы язамыни? Алайса гадиләреннән башла. Кьеркегор йә Ясперсны кабатла. Ярый, сөйләшү белән артыгын мавыгып киттек, ахрысы. Безгә инде күптәннән кичке ашны ашарга вакыт түгелме?

– Ул өстәлдә тора.

– Күрмим!

– Кантны начар өйрәнгәнсең. Аның атаклы сүзләрен исеңә төшер: «Аның анда булмаганын белсәм дә, караңгы бүлмәдә кара әйбер күрәм».

– Акыл сатма! Минем чынлап та ашыйсым килә!

– Мин Кантны аңлау дәрәҗәсенә күтәрелә алмаган кешене туйдыра алмыйм!

– Тәк, мин анда нәрсә эшләргә сүз биргән идем әле?.. Чүпне чыгарыргамы? Хәзер, күз ачып йомганчы чыгарып керәм. Кем әйткәне исемдә түгел инде, ләкин тормышта һәрвакыт батырлык өчен урын бар!



СЕЗ БЕЛӘСЕЗМЕ...

Хайваннарны яклаучыларны кешеләргә карата нәфрәт буенча танып була.

Кошлар ояларын ятлардан нык саклыйлар, чөнки анда җыештырылмаган.

Мөгезборынның күзләре начар күрә, ләкин аның авырлыгы белән бу бәла түгел.

Скунс – ихтыяр көче ифрат көчле хайван.

Көя өчен авыр вакытлар җитте: кая карама – синтетика.

Александр ШУЛЬПИНОВ



Илья КРИШТУЛ



Утыз мең ел элек тау куышында яшәүче бүре, тамак ачуы чиктән ашкач, бөтен булган кыюлыгын җыеп, кешеләр янына азык эзләп чыккан. Аны башта, үтеререп, ашарга теләгәннәр, ләкин өстенә тире япкан йонлач кеше тамак төбе белән нәрсәдер кычкырган, һәм бүрегә кимерелеп бетмәгән мамонт сөяге ыргыткан. Бүре аны рәхәтләнеп ашаган, һәм бу олы җанлы, акыллы затлар яныннан беркая да китмәскә булган. Бераздан ул шикле авазларга өрергә, торак яныннан зур аюларны куып җибәрергә һәм ыруның милкен шакаллардан сакларга өйрәнгән. Аннан соң ул ирләр белән ауга йөри башлаган, тамырлар җыеп йөрүче хатыннарны саклаган һәм караусыз калган кеше балаларына күз-колак булып торган. Моның өчен аны туйганчы ашатканнар, ә кайчагында хәтта тиреләр өстендә аунарга да рөхсәт иткәннәр.

Бер ел элек кызыма мәгарә бүресе токымыннан Микки исемле көчек бүләк иттеләр. Бу чихуахуа кисәге шунда ук азык эзләп кухняга килеп чыкты. Мин аны бәреп үтермәкче булган идем, ләкин хатыным тамак төбе белән нидер кычкырды һәм шул мәхлукка колбаса турап бирде. Корсагын тутыргач, Микки, рәхмәт-нисез, бу җылы фатирдан беркая да китмәскә карар кылды. Бер атнадан мин, күрмичә, аның тәпиенә бастым. Ветеринар безгә 5000 сумга төште, ә миңа моннан соң фатир эчендә ул караватта ятканда гына йөрергә рөхсәт ителде. Юк, кайчагында миңа да караватта аунарга рөхсәт итәләр, ләкин һаман сирәгрәк һәм сирәгрәк. Микки кешеләргә гомумән өрми, үзен тәмтом белән сыйлаучыларны гына ярата, милекне сакламый, бөтен нәрсәдән курка һәм калтырый, "кыз"ларга исе китми, чөнки ул токым биру мөмкинлегеннән мәхрүм ителгән. Һава суларга ул минем кулда чыга, үз аякларында өч метрдан артык үтми, бәдрәфкә фатирның иң җылы почмагында җәелгән чүпрәккә йөри. Ул чүпрәкне миңа юдыралар, чөнки ул минем кайчандыр яратып кигән свитерым – Микки аны беренче көнне үк шул максат өчен үзе сайлап алды. Тагын әле мин аны педикюрга һәм махсус эт стилистына йөртәм, шуңа күрә ул бәдбәхет мине хезмәтче һәм акылсыз зат дип саный. Ничектер бер көнне суыткычтан хатын Миккиның туган көнен билгеләргә дип алган күркә фаршын алып кыздырып ашадым. Һәм моның өчен миңа өч көн подъездда яшәргә туры килде. Моннан соң мин беркайчан да фарш урламадым. Ә беркөнне мин аның тешләрен минем теш щёткасы белән чистартканнарын күрдем, өстәвенә, аны җентекләп дезинфекцияләмиләр, ә чистартканнан соң шул килеш минем стаканга ыргыталар. Һәм юганнан соң аны минем сөлге белән сөртәләр...

Бервакыт аңа комбинезонын һәм ботинкаларын кидергәндә шнурларын артыграк тарттырганмын. Минем ыру хатыннары моны тәрәзәдән күреп алганнар, ахрысы, чөнки шуннан соң урамга йөгереп чыгып, кулымнан этне тартып алдылар. Соңыннан хатыным миңа аерылышу белән янап, хайваннарны кимсеткән өчен судка бирәм, дип йөрде.

Әгәр дә утыз мең ел элек борынгы кешеләр, мәгарә бүресенә мамонт сөяге ыргыту урынына, аны үтергән булсалар, мин элеккечә шатлык һәм бәхет диңгезендә йөзгән булыр идем.

Һәм кыздырылган күркә фаршы ашар идем.

Игорь КИЙКО



Анастасия ВАСИЛЬЕВА



Василий АЛЕКСАНДРОВ



Абау!

СҮГЕНҮНЕҢ БӘЯСЕ

Краснодар краеның Отрадное районында рус теле укытучысына сигезенче сыйныф укучысының әшәке сүзләр белән сүгенүенә бик ачуы килгән. Ул аңа Хемингуэйны бәләкәй чагында сүгенгәннән соң, әнисе авызын сабын белән юарга мәҗбүр итүе турында сөйләгән. Укытучы үсмергә шулай ук итәргә тәкъдим иткән, һәм ул риза булган. Яшь тел остасының ата-анасы мәктәпкә дәгъва белдермәсәләр дә, укытучы мәктәптән үз теләге белән киткән. Мәктәп директоры да үз урынын калдырачак.

ФОРМА КИГӘН КАРАК

Мәскәүдә яшәүче берәү подъезддан велосипед урларга булган. Ялгыш очраган кешеләрдә шик-шөбһә тумасын өчен, ул юл инспекторы формасы кигән. Ләкин хәйлә ярдәм итмәгән. Тротуарда тәртип саклаучы ялгыз инспектор ишегалдындагы әбиләрдә зур кызыксыну уяткан. Форма кигән карак велосипедка утырып каядыр җилле генә китеп баргач, алар тиешле урынга хәбәр иткәннәр. Аны тиз арада тоткарлаганнар.

ИШЕК ИНТЕЛЛЕКТЫ

Илебез башкаласында яшәүче бер ханымның фатир ишеген урлаганнар. Иң кызыгы шул, ул гади генә түгел, ә "акыллы" ишек булган. Ишек хәрәкәт датчиклары һәм саклау системасы белән җиһазландырылган булган. Әмма каракны бу туктатмаган, ул аны салдырып алган да китеп барган. Фатирдагы бөтен нәрсә үз урынында калган. Ишек интеллектын яклаучылар "акыллы" ишекнең максаты үз-үзен түгел, ә фатирны саклау булган дип аңлаталар. Шуңа күрә ул вазыйфасын үтәгән дип санарга була икән.

ОРБИТАДА ТУЙ

Аферист-мошенниклар кеше алдауның космик биеклекләренә ирешкәннәр. 65 яшьлек япон хатыны танышулар сайтында рус "космонавты" белән танышкан. Югары хисләр икесенең дә башын әйләндергән, һәм алар өйләнешергә булганнар. Тик кавышу бер киртә булган: гашыйк "космонавт" космик станциядә булып чыккан. Яшь кияүне салкын галәм кочагыннан алып чыгару максатына кайнар йөрәкле ханым аңа 30 мең доллар күчергән – Җирдән махсус ракета җибәрү һәм вак-төяк чыгымнар өчен. Әмма акча барыбер җитмәгән. Шуннан соң инде япон хатыны полициягә мөрәҗәгать иткән. Анда аңа чын галәм чиксезлегенең асылын аңлатып биргәннәр.



Виктор БОГОРАД



Алексей МАМАЕВ



Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

Бушлай квота

"Башыңа бәла аласың килмәсә, багучыга барма", диләр халыкта. Багучыга бармасам да, башыма бер бәла алдым...

Бервакыт күзләрем начар күрә башлагач, күз врачына мөрәҗәгать итәргә булдым. Әйбәт врач туры килде. Карады да күзләр буенча бер медицина үзәгенә барырга тәкъдим итте. Ярый, бу мәсьәләгә квота бар икән. Шулай итеп, язылдым мин күз белгечләренә. Билгеләнгән көнне килдем. Бушка үтүчеләр минем шикелле күп икән. Җиде-сигез кешене аппаратлар куелган бер бүлмәгә керттеләр. Врачлары да шактый. Мәнә берәүне урындыкка утыртып, күзенә дару тамыздылар. Ул икенче урындыкка күчте. Аның урынына башка кеше утырды. Шулай итеп, конвейер буенча, берәм-берәм, бер-беребезне алмаштырып бүлмә буенча йөрдек. Соңыннан бүлмәдән чыгасың да коридорда утырып торасың. Аннары бүлмәдән язу чыгарып тоттыралар.

Мәнә мин дә бүлмәдән чыктым. Күзләрем тамызган дарудан берни күрми, барысы да томанда. Кулымда язулары. Томанлы булса да, күреп алдым, минем исем-фамилия түгел. Кабат кереп киттем.

– Ярар, бераз көтегез, хәзер дөресләрбез, – диделәр дә бераздан икенче язу бирделәр. Исем-фамилия зур хәрефле язылгач, күрдем, үземнеке икән. Шул язу белән өйгә кайттым. Күзләрем бераз яхшырак ачылгач, калган язуны да укый башласам... адресы минеке түгел. Тагын бутаганнар. Инде нишләргә? Шалтыраттым шул ук клиникага.

– Фәлән-фәлән көнне килерсез. Дөресләп бирербез, – дип өметләндерделәр.

Әйтелгән көнне тагын барырга туры килде.

– Сез бит конвейер буенча халыкны керттегез. Бәлки берәрсенә минем язуны биргәнсездер, – димен.

– Юк, адрес кына ялгышкан. Калганы сезнеке, – диделәр.

Адресын алыштырдылар. Мин язуларын укып тормыйча, өйгә юл тоттым.

Инде өйдә күзлегемне киеп укый башлаган идем, абау... диагнозларым бөтенләй минеке түгел ләбаса?! Анда ниләр генә язмаганнар! Нинди генә күз авыруларым юк икән. Әллә никадәр операцияләр кичергәнмен. Башка ул якка аягымны да атламадым. Юлы да бик якын түгел. Үземнең врачыма барып, шундагы кәгазьләрне тоттырдым да:

– Мин анда бүтән бармыйм, үзегезгә генә йөрим, – дидем.

Шундый була икән ул бушлай – квота буенча дәваланулар.



Мордва ядкаре

Мордва – бүгенге көнгә кадәр үзенең үзенчәлекле культурасын саклаган бай һәм катлаулы тарихлы уникаль халык. Бу халыкның эчендә ике халык яши дисәк була – мокшы һәм эрзя. Аларның һәрберсенең үз әдәби теле, гореф-гадәтләре, хәтта кыяфәтләре дә аермалы. Аларны берләштергән нәрсә – катлаулы тормышка шаярып карау сәләте.

Мордва юморы – мокшыныкы, эрзянеке дә, төрле такмаклар, әйтемнәр, такмазалар һәм, әлбәттә, әкиятләрдә яши. Соңгылары – яшәеш зирәклеге генә түгел, ә тере халык сөйләме, җор һәм үткен авыл теле мисалы булып тора.

ЯЛКАУ ХАТЫН

Эрзя әкияте

Ялкау кызын күрше авылга кияүгә озатканда әнисе аңа үгет-нәсыйхәт биреп калган: «Иң мөһиме – йон эрли торган таракны һәм орчыгыңны онытма, вакыт-вакыт кулыңа алып тор».

Кыз әнисенең киңәшен онытмаган: кая гына барса да, нәрсә эшләсә дә, тарак белән орчыкны калдырмый: кулына алып-алып куя икән. Сез аны йон эрләгән дип уйлыйсызмы? Юк, кулында тотып тора да кире куя. Әнисеннән алып килгән киемнәрен бөтенләй туздырып бетергән, ярым ялангач йөри башлаган. Ә әнисе янына кунакка кайтасы килә – ялкау кыз ашап-эчәргә бик тә ярата икән.

Җыенгач, ул иренә әйтә икән: «Әни янына барганда, арбага саламны күбрәк сал – мин аның астында яшеренермен. Ә әнигә кызың соңрак килеп җитәр, диген. Кичкә таба мин өйгә керермен һәм юлда миңа юлбасарлар һөҗүм итте, әнигә дигән күчтәнәчләрне талап алдылар һәм үземне дә чишендереп киттеләр, диярмен!»

Алар шулай иткәннәр дә. Ир кайнанасы янына килеп төшкән, кунак җыйганнар, мәҗлес башланган. Тиздән кунаклар исерешә башлаганнар: кем җырлый, кем бии, кем көлә, ә кемдер елый икән... Караңгы төшү белән, кыз мыштым гына өйгә кергән, мич башына менгән, аннан сәндерәгә күчкән, һәм, иелеп, күзәтә башлаган. Иелә торгач, нәкъ өстәл уртасына очып төшкән бу. Өстәлдәге бөтен сый түгелеп-чәчелеп беткән, өстәл авып киткән. Кунаклар, куркып, качышып беткәннәр, кияү генә берни булмагандай утыра икән. Ул хатынынннан сораган: «Кайда йөрдең? Нигә ялангач син?!» Ул елый-елый, икесе уйлап чыгарган әйберне сөйли башлаган. Әнисе кызының исән-сау булганына бик шатланган һәм аны тиз генә киендереп куйган.

– Күчтәнәчләрнең юкка чыгуы бәла түгел, – дигән әнисе, – иң мөһиме, үзең исән. Ә тарак белән орчык кайда?

– Алар исән, әни, исән...

– Исән икәнен күреп торам, һәм син аларны кулыңа алырга онытмыйсың икән! – дигән әнисе һәм хәйләкәр елмаеп, яшьләргә карап куйган.

ЭТ НИЧЕК ҮЗЕНӘ ДУС ТАПКАН

Мокшы әкияте

Кайчандыр эт берүзе урманда яшәгән ди. Берзаман аңа күңелсез булып киткән. Һәм ул үзенә дус эзләргә чыгып киткән. Бара, бара икән бу урман буйлап, ни күрсен – каршысына бүре килә. Эт аңа әйтә икән:

– Бүре, әйдә, бергә яшик.

– Әйдә! – дигән бүре. – Икәүләшеп күңеллерәк булыр.

Караңгы төшкән, йокларга ятканнар болар. Төн уртасында эт торып өрә башлаган. Бүренең йокысы качкан. Бик курыккан бу, һәм этне сүгә башлаган:

– Син нәрсә өрәсең? Менә аю килер дә икебезне дә тотып ашар.

«Юк, – дип уйлаган эт, – начар дус булды әле бу, көчле дә түгел, аюдан курка. Бәлки, аю-баһадир иң көчлесеедер".

Бүрене калдырган да аюны эзләргә киткән бу. Бара урман буйлап, ә каршысына аю килә.

– Әй, аю-баһадир, әйдә бергә яшик, – дигән эт.

Аю риза булган. Көне буе бергә йөргәннәр болар, төн дә килеп җиткән. Аюның йокымсырый гына башлавы булган, ә эт торган да өрә башлаган. Аю куркып уянган, үзе калтырый икән. Этне сүгә башлаган:

– Тукта, – ди икән. – Нәрсә өрәсең? Кеше ишетер дә икебезне дә килеп үтерер.

«Их, – дип уйлаган эт, – монысы да куркак булып чыкты. Кешене эзләргә туры киләчәк».

Һәм эт аюдан китеп барган. Урман аланында кешене очраткан һәм аңа әйтә икән:

– Кеше, әйдә бергә яшик!

Кеше риза булган һәм аны өенә алып кайтып киткән. Төн уртасында эт өрә башлаган. Кеше уянган да, кычкырган:

– Әй, эткәем минем, әгәр ач икәнсең, аша, ә миңа йокларга комачаулама!

Эт ашаган да йокларга яткан. Шуннан бирле ул кеше белән яши башлаган.





Алмаз ХӘМЗИН

ТУК КЕШЕДӘН ЗУР АРТИСТ ЧЫКМЫЙ

Әле менә бәләкәй чактагы иськә төшкән хатирәләр белән кайнашып утырам. Иң беренчесе, нигәдер, күренекле нәфис сүз остасы дип әйтәбез бит инде аны – Әзәл Яһудин булды бугай... Үземә ничә яшь булганын да әйтә алмыйм. Концертфәлән килсә дә авылга, клубка алып чыгып әниемнең яки әбиемнең алдына утырырлык чагым да түгелдер, мөгаен.

Ул килгән көнне миңа концерт карау бәхете тимәде. Әти-әни киттеләр, ә мин әби белән өйдә калдым. Бабай кайда булгандыр, белмим, хәзер чамалап кына әйтәм, берәр җиргә йорт салырга киткән чагына туры килгәндер... Ярый, сүзем бу турыда түгел, Әзәл Яһудин турында иде бит. Шулай... әби мич каршындагы өстәлдә бәлеш әмәлләү белән мәшгуль. Инде утыннар янып бетә язган, чарт та чорт күмер ата. Кайбер идәнгә төшкәннәрен әбием ялан кулы белән ала да кабат мичкә ата. Ничек кулы пешми, диген?..

Бәлеш – минем иң яраткан ризыгым. Пешеп җиткәнче үк авыз суларым килеп тора. И-и, рәхәт тә инде шуның тәмле исе чыгып калулары. Бу бәлешне бәләкәйрәк итеп салды түгелме соң әби? Теге кунак артист абыйга гына микән әллә ул, ә?

Шулай икән шул: абзый кеше кайтты да әбинең комганнан агызып торган җылы суы белән кулын юды. Нидер сөйләнә мулла кебек. Түр яктагы өстәлнең түренә барып утырды да кулындагы сөлгесен күлмәк якасының астына кыстырды. "Алла-алла, бигрәк кылана!" – дип куйган идем әле мин ул чакта, бәләкәй генә булсам да.

Менә әби табасы белән алдына бәлешне чыгарып утыртты. Пычак белән кисеп, өстен ачты. Һәрвакыт миңа тиясе бөкесе тегенең авызына кереп качты. Минем елардай булып сытылган йөземне күрепме, әбием кулымнан тотты да, арткы бүлмәгә өстерәп диярлек алып чыкты, ике арадагы ишекне тыгызлап ябып куйды. Һәм: "Комачаулама!" – дип, бармагы белән янап алды.

Миңа нәрсә? Әби һаман мич алдында нәрсәдер эшли, әллә кабартма пешерә шунда?.. Мин ишек тирәсендә кайнашам. Өстәрәк торган ишек тоткасына буем җитми, ләкин чалыш ишекнең аскы касыгында ачыклык бар – шуннан каерам. Азрак ачылган ярыктан тегенең ашаганы күренә. Карап торганымны сиздe, ахрысы – күзе миңа төште. Иягеннән дуңгыз борыны ясап, миңа күрсәтә. Үзе умырып бәлеш ашый. Ишекне киңрәк ачып, кермәкче генә булам, әби килеп җитә дә мине янадан артка өстери. Мин тагын ишеккә тынгы бирмим. Әби тагын килеп җитә. "Мишәйт итмә, абыеңа!" – ди. Тәки берүзе ашап бетерде бит теге бәлешне, ник бер каптырсын! Бирән!

Бу вакыйгадан соң бик күп еллар үтте. Инде үзем хәзер аның кебек зур артист дип әйтик. Аның белән кайчак очрашкалап тордык, бергәләп концертлар куйдык. Шунда әйткәли идем:

– Әзәл абый, син бит теге вакытларда миңа бер кашык әбием пешергән бәлешеңне жәлләдең... – дип.


– Кайда, кайчан?! – ди.

– Мин бәләкәй чагымда, безгә кунарга кергән идең концертлар куеп йөргәндә, – дим. – Бер кашык бәлеш кабарга тилмереп күзеңә карап тордым бит! Бирүзең бер бәлешне!

Ни әйтергә дә белмичә торды зур артистыбыз, ни әйтергә дә!

Шулай да, алагаем бәлеш пешереп, өйләренә чакырган иде хәләл җефете белән – бик нык кунак иттеләр. Ач студент чакларымда булды бу... Рәхмәт!

- Тук кешедән зур артист чыкмый, энекәш, минем дә шундый чагым булгандыр. Без бит ул чакларда тамак хакына эшләп йөрдек, – диде.



– Авторны! Авторны!

Иосиф БОБРОВИЦКИЙ, 1963 ел.



Леонид ЕЛЬКОВИЧ, 1964 ел.



• • •

– Син ничек мондый күркәм, ыспай гәүдәңне саклый алдың?

– Мин бит мәрмәр төсле сыер ите һәм лосось балыгы ашыйм.

– Ләкин бу бик мәшәкатьле бит!

– Менә шуңа күрә дә саклана инде ул яхшы фигура.

• • •

Без яңа заман хәерчеләре: безнең кыйбат смартфоннарыбыз һәм компьютерларыбыз бар. Алар ярдәмендә үзебезнең интернет-банкларыбызга керә алабыз һәм счётларыбызда бер тиен акчабыз да юклыгына инанабыз.

• • •

– Кайчан син миңа тәкъдим ясыйсың?

– Нәрсә инде, безнең бит синең белән болай да барысы да яхшы.

– Миңа барысы да яхшы булуы кирәкми. Минем кияүгә чыгасым килә.

• • •

– Әгәр дә бездән комсызлык, көнчелек, мәкерлек, әшәкелек бетеп, тугрылык, гаделлек, дуслык һәм ярату хисләре генә калса, нәрсә булыр иде?

– Безгә йон үсәр иде, койрык калкыр һәм без эткә әверелер идек.

• • •

Бер ир, ишегалдына кергәндә, йорты каршыдагы стоянкадан күршесенең машинасын урлаганнарын күреп ала, һәм аптырап калмый, бушаган урынга үз машинасын куя.

• • •

– Син кем булып эшлисең?

– Ландшафт дизайнеры булып!

– Ай-яй! Компьютердамы?

– Юк... Бульдозерда...

• • •

Классташлар – гаҗәеп шәп сайт. Анда минем дуслыкка түшәм тарттыручылар, пластик тәрәзәчеләр, штора-пәрдәләр һәм шкаф-купелар куючылар сораналар. Мәктәптә минем белән андый укучылар булганын һич хәтерләмим.

• • •

– Суыткычны ачсам, анда боулинг.

– Ничек инде?!

– Шар тәгәрәтергә була.



Виктор ФЁДОРОВ



Михаил ЛАРИЧЕВ



БИТАРАФЛЫК

Кадерле редакция! Константиновка бистәсенең Үзәк урамында урам аркылы җәяү чыгу өчен уңайлык тудырылмаган. 47 нче номерлы мәктәп укучылары үзләренең тормышларын куркыныч астына куеп, юл аша чыгып йөриләр, ашыкмыйча булса бер хәл – алар бит як-ягына карамыйча йөгерәләр, физкультура дәресләрендәге кебек кенә түгел. Бу мәсьәләне чишәргә тиешле кешеләрне бары тик юл тәртибен саклау кагыйдәләрен үтәү генә борчый.

Җәяүлеләр өчен юл аркылы чыгу корылмасы булдыру үтенечләренә җаваплы оешмалар салпы карашта. Янәмәсе, бу урында аны эшләү мөмкин түгел... чөнки юл хәрәкәте кагыйдәсенә каршы килә. Менә сиңа мә!.. Зебра ясап кую, юл кырыйларында тротуар булу, ул тирәләрне яктырту – Үзәк урамда булырдай гамәл түгеллеге көн кебек ачык. Баганалар утыртып, лампалар элергә бик авыр эш микәнни? Ә менә балаларның тормышын куркыныч астына ташлау, һәр мизгел туып тора.

А. НУРУЛЛИНА

КАЗАН

НИЗАГ

Кадерле "Чаян"! Халык әйтсә, хак әйтә: йорт сатып аласың килсә, иң беренче уйла: күршеләрең кем була. Моңа хәтле, без – Кече Кабан авылы кешеләренә яшәү оҗмах булган икән – тирә-ягыбызда кырлар, болыннар, урманнар. Юкка түгел иде шәһәрдәге фатирларыбызны сатып монда күчүебез – табигать кочагында гомер итү рәхәтендә коену иде хыялыбыз. Ләкин рәхәтнең кайчан да булса чиге була. Күптән түгел безнең борын төбендә торак комплексы төзи башладылар.

Төзүчеләр безне тынычландырырга тырышты: йортлар өч каттан да биек булмаячак, мәктәп төзиячәкләр, балалар бакчасы һәм дәвахәнә салачаклар. Әмма аларның нәфесләре үсеп китте. 10-12 катлы шәһәр йортлары калка башлады һәм бу торак комплексы аркылы олы юл да үтәчәк икән. Ә менә әлеге дә баягы инфраструктура дигәннәрен шул шәһәр халкы гына файдалана алуы мәгълүм булды.

Менә шундый авыл белән шәһәр арасындагы аермалык бетү үзенчәлеге барлыкка килде!


Кече Кабан авылы халкы

ЛАЕШ районы





Александр ШУЛЬПИНОВ



Виктор ФЁДОРОВ

Николай ВОРОНЦОВ



Василий АЛЕКСАНДРОВ





Күренекле татар язучысы, драматург, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, "Мәгариф өлкәсендәге казанышлары өчен" медале лауреаты, Ф. Хөсни, Д. Сиражиев, Т. Миңнуллин исемендәге премияләр иясе Рәдиф Нәҗип улы СӘГЪДИЕВкә – 65 яшь.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Язмасаң да "Чаян" дустыңа,
Беләбез хөрмәтеңне...
Уйлыйсың, фикерең безнеңчә –
Сугәсең халәтеңне.
Яһүд булып беткәнсең инде –
Көләсең гел үзеңнән.
Үзеннән көлә белгәннәр дә
Үтә цензор күзеннән.

Алмаз ХӘМЗИН

Юбилеең уңаеннан бер юморесканны укучыларыбыз игътибарына тәкъдим итәргә булдык.

ТАМА... ДА

Рәтле хезмәт хакы түләнмәгәч, артистлыктан киттем мин! Түземлегем бетте! Үземне кол, холоп, батрак, бурлак итеп сизә башладым. Түзмәдем, киттем инде ниһаять. Яраткан тамашачыларымны калдырып киттем. Мескенлегемне яшереп, ясалма чырайлар ясап, алар каршында бәхетле булып кыланып, елмаеп уйнавымны ташлап киттем. Нигә, икейөзле булып кыланырга?! Кешелегемне дә саклап калырга кирәк бит. Кем шул хәерче хезмәт хакына риза, шулар калды! Ә мин киттем, табигать биргән осталыгымны кызганып киттем. Теләсәң, гармун-тальянында уйныйм. Теләсәң, күпләр кызыгырлык итеп җырлап бирәм. Сүз осталыгым да җитәрлек. "Тамада" мин хәзер. Нәрсә, нәрсә? "Шәп тама да", дисезме! Ялганламыйм, әйбәт тама! Ниһаять минем талантым да яхшы бәяләнде. Бае да, түрәсе дә өенә генә чакыра. Мулдан сыйлый, мулдан түли дә! Кая барсын түләмичә, минем кебек осталарны табып кара әле! Бармак белән санарлык. Ә мин мактыйм, аңа багышлап җырлар җырлыйм. Каршысында биеп җибәрәм хәтта. Ышана теге, үзен Ходайдан да, халкыннан да бөек диеп уйлый! Үзенең намуссыз, мәгънәсез адәм икәнлеген уена да китереп карый алмый...

Миңа нәрсә, миңа барыбер, акчасын гына түләсен! Эшли торгач фатирның да кәттәсен сатып алдым, дачам, машинам да кеше кызыгырлык. Туган көннәр, юбилейлар, төрле чараларның чиге юк. Чират торалар... Теге, кемдер әйтмешли: "Пир во время чумы" кебек. Сыйнигъмәттән өстәлләр сыгылып тора.

...Тик барыбер соңыннан күңел болгана, малай! Юк инде, юк, эчкәннән түгел. Эштә, гомумән, эчмим мин. Хатын әйтә: "Майлы әйбер күбрәк ашыйсыңдыр", – ди. Алай да түгел инде. Укытучылар, артистлар, табиблар – илнең алдынгы кешеләре иң бай илдә иң хәерче илдә яшәгән кебек тормыш итсеннәр әле! Балаларын укыткан, дәвалаган, ашаткан халкын мыскыл итеп, типтереп яшәгән түрәләр тагын кая бар?! Иң бай ил бит бу! Шуларны икейөзләнеп мактап сөйләвем укшыта мине. Кая барасың! "Тамада..." мин хәзер. Илем бар барын, рәхәтен генә күрә алмыйм...

Фәнзаман БАТТАЛ

Тырышлыкка шайтан төкерә

Ул-бу хата киткәннән соң яки китә язганнан соң, баш мөхәррирләр, үз коллективларының җаваплылыгын көчәйтү һәм сизгерлеген арттыру максатында, "конкрет катгый чаралар күрәләр". Җитди утырышларны әйткән дә юк инде... Кемгәдер – шелтә, кайсынадыр кисәтү бирәләр, кайберәүләрнең алдына орфографик сүзлекләр салалар: сүзнең дөреслегенә әз генә шикләнсәң дә шуны ачып карарга иренмә, янәсе. Бер уйласаң, хата китүгә бернинди дә юл калмаган кебек...

Хәтердә, чираттагы хаталарның берсеннән соң, коллективны бик һәйбәтләп "эшкәрттеләр". Аннан соң, чираттагы гәҗитне әзерләдек тә, гранкаларны, полосаларны (колонкаларны, битләрне) һәркемгә диярлек өләшеп чыктык. Тырыштык мәгәр, хаталарны серкәләр эзләгәндәй эзләдек. Әзер гәҗитне өстәленә салып "БАСАРГА! "дип соңгы имзаны куйганда, мөхәрриребез зур канәгатьләнү белән кинәнде: "Менә бу санда хата калмаганга иманым камил минем. Киләчәктә дә шулай эшләрбез, егетләр, иренмәбез. Аның каравы – йөзебез чиста булыр".

Чистарды, ди... Икенче көнне, эшкә килеп, берәр сәгать эшләргә өлгердек микән, райкомның пропаганда бүлегеннән шалтыраталар...

(Ни дип шалтыратуларын әйтим дигәндә генә, олуг язучыбыз Мөхәммәт ага Мәһдиев искә төште. Үзара сөйләшкән чакларда: "Телефон шалтырады", дип язу хата ул, Фәнзаман! "Чылтырады", "чылтырый" дип яз", – дип ялвара иде. Минем кебекләргә әйтеп-әйтеп тә кермәгәнгәдер, шушы фикерен куәтләп, матбугатта да язып чыккан иде. Күрәмсең, өендәге телефоны чылтырый торган булгандыр – дус яшәп тә фатирында булырга туры килмәде. Хәзер инде аппаратларның тавышлары кырык төрле: шалтырыйлар, чылтырыйлар, челтериләр, гүелдиләр, пипелдиләр, уһылдыйлар, сайрыйлар. чырылдыйлар, хәтта җырлыйлар да. Ә без яшь чакта бары тик шалтырыйлар иде.)

Шулай итеп, райкомнан шалтыраталар:

– Нишләп сез анда райкомга төкереп ятасыз?! Оягыз белән бюрога куйдыртам, фәлән-фәсмәтәннәр!..

Йа Алла, монысы ни дигән сүз инде тагын! Дөрес әйтә икән бит югарыдагы абзыебыз. Райкомга гына түгел, район советы башкарма комитетына да төкергәнбез...

Өлкәнрәкләрнең барысы да хәтерлидер әле: ул чорда ай, квартал, ел ахыры саен райком белән райбашкарма, социалистик ярышка йомгак ясап, алдынгы хуҗалыкларны, кешеләрне зурлап, арттагыларын хурлап дигәндәй, карарлар чыгаралар иде. Район гәҗитләренең һәркайсында да алар "КПСС райкомында һәм район советы башкарма комитетында" дигән шаблон исем белән гәҗитнең беренче битендә басыла килделәр. Менә шул карарның бер пункты гәҗитебездә болай басылган: "КПСС райкомына һәм район Советы башкарма комитетына кыхпыхтфушыртчурт пыхипсишарт хырпыр..." Исебез-акылыбыз китте. Шундый "изге" карарга каян килеп кергән бу кәмит?! Соңыннан аңлашылды. Линотипта хәреф җыючылар, машиналары әйле-шәйле эшли башласа, сынап карау, көйләү өчен теләсә кайсы хәрефләргә баскалап "проба" ясыйлар һәм кургаштан коелган ул юлларны шундук чүп савытына ташлыйлар иде. Гәҗиткә шул юллар кереп оялаган! Ә инде хатадан арындырылган, шул "тишеккә" тыгылырга тиешле өч юл чүп чиләгенә очкан... Әйе, аңладык. Ләкин ни файда: эш үткән, пешәсе борчак пешкән. Бюрода безнең аңлатуны колакка да элүче булмады. Хуҗабызга – Фәрит абыйга – партийный выговор чәпеп, барыбызга да ачык күз белән эшләргә боерып, куып чыгардылар.

...Мин күп мөхәррирләр кулы астында эшләдем. Ләкин Фәрит абый Хәбибуллин кебек сагынып искә алырлыклары икәү-өчәү дә булмады, ахрысы. Редакциясендә эшләүче каләмдәшләренә үрнәк булырдай итеп яза белүче мөхәррирләр һәрвакыт диярлек юк санында булды һәм, кызганыч ки, хәзер дә шулай. Вакыты-вакыты белән "Социалистик Татарстан"ның үз хәбәрчесе дә булып эшләгән Фәрит абыебыз талантлы, туры сүзле, гадел һәм киң күңелле шәхес иде, мәрхүм. Шикләнмим, урыны, һичшиксез, оҗмахтадыр... Күңелсез вакыйгалар вакытында да безнең күңелләрне бер мизгелдә кара юшкыннан арындыра белә иде. Теге бюродан соң да, бераз моңаеп утыргач, кинәт ачылып китеп, сабыйларча матур итеп көлеп җибәрде:

– Башыгызны имәгез, егетләр. Бер караганда, райкомнар шул кыхпых-тфүгә генә лаек нәрсәләр инде. Ләкин, аң булыгыз, моннан соң хата китәрлек булмасын. Безне укучы халык бар. Аның алдында кызарудан сакланыйк.



САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

1923 елдан чыга.

№ 11 (1924) ноябрь 2022

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ, Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.

420047, Казан шәһәре, Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәмендә оештырылган.

Журнал Роскомнадзор идарәсендә теркәлде. Теркәлү саны һәм вакыты: ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.

«Журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша язылa алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).

Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 01.11.2022 ел.
Тираж – 2518 Заказ О-3153

Редакциянең адресы: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Белешмәләр өчен телефоннар: (843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru

16+

Бәясе ирекле

Уйна да, уйла да!

ЖЫРЧЫ ФӘХРИ ...

КОМПОЗИТОР РЕЗЕДА ...

МУЗЫКА КОРАЛЫ

3

КОМПОЗИТОР ... ХӘСӘНОВ

"... СӘЯХӘТ" (ЗӨЛФӘТ ХӘКИМ)

"КАРА ДА ГЫНАЙ ..."

"... СУЛАР ГЕЛ ШУЛАЙ"

"... ГЕЛ СИҢА АШКЫНАМ"

ГРЕК МИФОЛОГИЯСЕНДӘ АПОЛЛОННЫҢ УЛЫ

МАКТАУ ШИГЫРЕ

ХӘРБИ НЫГЫТМА

ЯЗУЧЫ СӘГЫЙТЬ ...

«КАРЛЫГАЧЛАР ... ЯСЫЙ»

... ИЛЬЯСОВ

НОТА

6

7

ЖЫРЧЫ РУСЛАН ...

"СУТЫЙ"

4

"ЙӨРӘКЛӘРДӘ КАЛА ...СЫ"

16

2

ТУПНЫҢ КАПКАГА КЕРҮЕ

"КИЛ ... ИДЕЛНЕҢ ЖИЛӘС ЖИЛЕ"

ТЕРЕ ... (ДАНЛЫКЛЫ КЕШЕЛӘР ТУРЫНДА)

"... (-2) ИСЕ"

11

17

ШАХМАТТА КОРОЛЬНЕҢ ЖИҢЕЛҮЕ (-1)

НОТА

НУРИ ...

8

(-2) БӘЙРӘМ САЛАТЫ

...-СУ

"... КАНАТЫ АТ БУЛЫР"

"БАЛ ФАБРИКАСЫ"

БАЛЫК ШУЛПАСЫ

"ИРЕННӘРЕ ... ГЫНА"

САРЫК АВАЗЫ

...(-1) АЛУ

"ИРТӘНГЕ ..."

9

"ҮСЕП УТЫРА БЕР КАРТ ..."

"БЕР ТАУДА ... ЧИШМӘ"

13

... ТОЛСТОЙ

АННАН КАМЫР ЯСАЛА

5

1

— Ө хәзер аек ирләр өчен!

18

14

Светлана ...

Ф. КӘРИМ ШИГЫРЕ

15

10

12

Ринат АБЗАЛОВ төзеде



1. Бакчада тормыш бармы?

2. Бәхет нәрсә ул?

3. Ни өчен барлык кызлар бай ирләрнең хатыннары булырга хыялланалар?

4. Икенче бала табарга нинди этәргеч иң яхшысы?

5. Нәрсә ул сәламәтлек?

6. Рәсәйдә иң кыю кешеләр кемнәр?

7. Кешеләрне нинди ике дәрәжәгә аерырга була?

ЖАВАПЛАР

1. Бар. Әгәр дә анда хатының, кайнанаң һәм туталләрең булмаса. 2. Кешенең бар нәрсәсе дә житеш, бар теләкләре дә үтәлгән, ә үзе һаман ирекле. 3. Чынлыкта алар тол булып калуларын тели. 4. Беренчесеннән калган әйберләрне каядыр, кемгәдер кулланырга кирәк бит инде. 5. Бөтен жир авырта, әмма әле табибка бармаслык хәл бар. 6. Рәсәй түрәләренең балалары.. Алар НАТО илләрендә яшәргә курыкмыйлар. 7. Халык чаралары кулланып дәвалана, ә икенчеләре – халык жилкәсенә атланып.

Сынамышларны Гүзәл СӘҢГАТУЛЛИНА әзерләде

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда жыр исемен укыгыз. Журналыбызның 10 нчы санында басылган чаянвордның тикшерү сүзе – **«КЫР КАЗЛАРЫ КИТКӘНДӘ»**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Г. БАҺАВЕТДИНОВ (Чаллы),
Б. ШӘЙХЕТДИНОВ (Алексеевский р-ны, Урта Тигәнәле ав.),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан).

Җиңүчебез – Урта Тигәнәледән **Бәдретдин ШӘЙХЕТДИНОВ!**












4612750670080